ШИМБӘ
30 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 24 (6746)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

КОЛХОЗЛАРНЫҢ ИҢ БЕРЕНЧЕ БУРЫЧЫ

Безнең сөекле Кызыл Армиябез Көньякта, Көньяк - Канбатышта, Төньяк Кавказда, Воронеж, Волхов һәм Ленинград фронтларында уңышлы рәвештә һөҗүм сугышлары алып бара. Совет сугышчылары гаять зур уңышларга ирешәләр, немец-фашист бандитларны рәхимсезлек белән кыралар, дошманның җанлы көчләрен һәм техникаларын юк итәләр. Куәтле һәм көчле омтылыш белән алга, көнбатышка таба баручы Кызыл Армиянең дошманга ясый торган ударлары торган саен көчәя бара. Радио көн саен яңа шатлыклы хәбәрләр китерә. Йөзләрчә шәһәрләр, меңнәрчә авыллар немец оккупантларыннан чистартыла, меңнәрчә совет гражданнары немец фашистларының изүеннән һәм газабыннан коткарылалар.

Хәзер һәрбер совет сугышчысының, һәрбер хезмәт иясенең бердәм теләге— дошманны ничек кенә булса да тизрәк юк итү. Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы совет сугышчыларында һөҗүм дәртен тагын да көчәйтте. Юлбашчыбыз приказы безнең тылыбызда да гаять зур күтәренкелек тудырды. Һәрбер коллектив, аерым һәрбер эшче, һәрбер колхоз һәм колхозчы Кызыл Армиянең дошманны тизрәк тар-мар итүе өчен кулларыннан килгәннең бөтенесен дә эшләргә тырыша. Һәм башкача булуы мөмкин дә түгел.

Дошман җитди рәвештә яраланды һәм хәлсезләнде. Ләкин ул әле бөтенләй юк тар-мар ителеп бетмәгән. Ә ул, һичшиксез, юк ителергә тиеш һәм юк ителәр. Моңа совет кешеләре бер генә минутка да шикләнмиләр. Ләкин шул ук вакытта җиңү үзеннән-үзе килми, аны яулап алалар. Моның өчен исә тылның фронтка ярдәмен торган саен арттыра барырга, Кызыл Армия өчен танкларны, самолетларны, орудиеләрне һәм сугыш припасларын мул итеп җитештерергә, икмәкне, итне, майны һәм барлык азык продуктларын тулысынча җиткереп торырга кирәк.

Колхозларның һәм колхозчыларның иң беренче бурычы—Кызыл Армияне, аңа сугыш кораллары һәм припаслары җитештерүче промышленность эшчеләрен икмәк белән тәэмин итүдән гыйбарәт. 1943 нче елның 21 нче январенда В. И. Ленинның үлүенә XIX ел тулуга багышланган тантаналы-траур утырышында ясаган докладында иптәш А. С. Щербаков болай диде:

«Хәзер колхозлар алдында гаять әһәмиятле ике бурыч тора: беренчесе— дәүләткә ашлык тапшыруны тәгәлләү. Күп кенә өлкәләрдә инде ашлык тапшыруны тәмам иттеләр. Шулар белән беррәттән әле артта калучы өлкәләр һәм районнар да бар. Аларның бурычы—үзләренең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен иң кыска срокта тулысынча үтәүдән гыйбарәт». Ә безнең республикада исә әле үзләренең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәмәгән районнар һәм колхозлар шактый.

Әле күптән түгел ТАССР Совнаркомы Беренче Май районында дәүләткә ашлык тапшыруның барышын карады. Бу район үткән елны ашлык әзерләү планын быелның 20 нче январена нибары 31,6 процентка гына үтәгән. Бу район башка төр авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләүне дә өзгән. Эшлексезлек, гамьсезлек һәм җавапсызлык күрсәткән өчен район советы башкарма комитеты председателе Юсупов эшеннән алынып судка бирелде. Бу бик урынлы! Бөек Ватан сугышы шартларында мондый дисциплинасызлык күрсәтү—җинаять. ТАССР Совнаркомының карары артта калучы башка районнарның җитәкчеләре өчен дә сабак булырга тиеш.

Дәүләткә ашлык тапшыру—ул, колхозларның иң изге һәм иң беренче бурычлары. Димәк, ул бурыч, һичсүзсез һәм иң кыска срокта үтәлергә тиеш. Моны инде, бу өлкәдә артта калучы районнарның җитәкчеләре, ниһаять, аңларга һәм үзләренең эшләрен кискен рәвештә яхшыртырга тиешләр.

Кызыл Армиягә, илгә икмәк кирәк. Ә бездә ул бар. Бары тик җитәкчелек итәргә, ашлык тапшыру эшен үз агымына куймау гына кирәк.

Партия һәм совет оешмалары җитәкчеләренең бурычы ашлык тапшыруны иң кыска срокта үтәүдән гыйбарәт. Бу—иң мөһим бурычларның берсе.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

I

ВОРОНЕЖДАН КӨНБАТЫШТАРАК БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘРНЕҢ УҢЫШЛЫ ҺӨҖҮМЕ

Воронеждан көнбатыштарак урнашкан безнең гаскәрләр шушы көннәрдә немец-фашист гаскәрләренә каршы һөҗүмгә күчтеләр. Һөҗүм өч юнәлештән башланды: төньяктан, көнчыгыштан һәм көньяктан. Безнең гаскәрләр, дошманның көчле рәвештә ныгытылган оборонасын 70 километр озынлыкта өзеп һәм һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, каты сугышларның өч көне эчендә 40—50 километр алга киттеләр. Безнең гаскәрләр халык яши торган 200 дән артык пунктны алдылар, шул исәптән КАСТОРНОЕ шәһәрен һәм зур тимер юл узелы, район үзәкләреннән ВОЛОВО, ГОЛОСНОВКА, ЗЕМЛЯНСК, ГРЕМЯЧЬЕ, ХОХОЛ, район үзәкләре һәм тимер юл станцияләре ГОРШЕЧНОЕ, ЛАЧИНОВО, СЕМИЛУКИ, тимер юл станцияләре ЛАТНАЯ, КУРБАТОВО, ПРОКУРОВО, НАБЕРЕЖНОЕ алынды.

Безнең гаскәрләр, бөтен КАСТОРНОЕ юнәлешендә тупланган ударлар ясап, немец-фашист гаскәрләренең көнбатышка чигенү юлларын кистеләр.

Безнең гаскәрләрнең һөҗүме барышында немецларның 383 нче, 82 нче, 340 нчы, 377 нче, 323 нче, 57 нче һәм 68 нче пехота дивизияләре, 45 нче пехота дивизиясенең бер полкы һәм 299 нчы пехота дивизиясенең бер полкы тар-мар ителде. Бу берләшмәләрнең һәм частьларның калдыклары Касторноедан көнчыгыштарак районда безнең гаскәрләр тарафыннан тыгыз боҗра белән чолгап алындылар һәм юк ителәләр.

Сугышларның өч көне эчендә 14.000 нән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

Шул ук вакыт эчендә, тулы булмаган саннар буенча, безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: 107 танк, төрле калибрлардагы 340 орудие, 264 пулемет, 8.000 винтовка, 40 радиостанция, 1.217 автомашина, 307 мотоцикл, сугыш йөкләре төялгән 24 тимер юл эшелоны, сугыш припаслары, кораллар һәм азык тутырылган 36 склад.

Сугышларның өч көне эчендә дошманның үтерелгән солдат һәм офицерлары гына да 12.000 гә җитте.

Дошман оборонасын өзүне генерал-лейтенант иптәш М. А. РЕЙТЕР һәм генерал-полковник иптәш Ф. И. ГОЛИКОВ гаскәрләре тормышка ашырды.

Сугышларда танк гаскәрләре генерал-майоры иптәш Н. П. ПУХОВ, генерал-лейтенант иптәш Н. Е. ЧИБИСОВ, генерал-лейтенант иптәш К. С. МОСКАЛЕНКО, генерал-майор иптәш И. Д. ЧЕРНЯХОВСКИЙ гаскәрләре һәм генерал-майор иптәш М. И. ГЛУХОВНЫҢ һәм танк гаскәрләре генерал-майоры иптәш А. Г. КРАВЧЕНКОНЫҢ танк берләшмәләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

II

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР НОВЫЙ ОСКОЛ ҺӘМ КРОПОТКИН ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1) 29 нчы январьда Воронеж фронты гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, НОВЫЙ ОСКОЛ шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен алдылар.

Итальяннарның Альп корпусын юк итү һәм пленга алу тулысынча тәгәлләнде. Өстәмә рәвештә 11.000 итальян солдатлары һәм офицерлары, шул исәптән, үзләренең штаблары белән берлектә, дивизия командирлары булган генераллардан Уммерти, Батисти һәм Паскалини плен алынды. Шулай итеп, Воронеж фронтының бу участогында плен алынган солдатлар һәм офицерлар саны 28 нче январьда кичкә таба 86.000 гә җитте.

2) ТӨНЬЯК КАВКАЗ фронты гаскәрләре, каты сугышлардан соң, КРОПОТКИН шәһәрен һәм зур тимер юл узелын алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

КРЕМЛЬ

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш И. В. СТАЛИНГА

Явыз дошманны тар-мар итүгә барлык совет халкы белән берлектә кайнар омтылыш белән чолганган хәлдә һәм Кызыл Армиянең ватан сугышы фронтларында Сезнең җитәкчелегегездә ирешкән уңышлары белән рухланып, Оборона Наркоматының Үзәк идарәләре работниклары Кызыл Армияне коралландыруга үзләренең саклык акчаларыннан 3.080.000 сум акчалата һәм 4.155.000 сумлык дәүләт заемы облигацияләре керттеләр.

Средстволар җыю оборона Наркоматы работникларының ватаныбызга, большевиклар партиясенә, даһи юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталинга тирән мәхәббәтләре һәм бирелгәнлекләренең ачык демонстрациясе сыйфатында бара.

Немец оккупантларын тар-мар итү һәм аларны безнең җиребездән куып җибәрү өчен Оборона Наркоматы работниклары үзләренең бөтен көчләрен, бөтен белемнәрен бирергә Сезгә, иптәш Сталин, сүз бирәләр.

Сезгә, кадерле иптәш Сталин, чын йөрәктән кайнар сәлам җибәрәбез һәм Сезгә озак еллар яшәү һәм сәламәтлек телибез.

ССР Союзы Оборона Халык Комиссары урынбасары, Советлар Союзы Маршалы Г. ЖУКОВ.

Оборона Халык Комиссары урынбасары Кызыл Армиянең Баш Политик Идарәсе начальнигы генерал-лейтенант А. ЩЕРБАКОВ.

СССР Оборона Халык Комиссариатының Үзәк Месткомы председателе Е. БАХАРЕВА.

ССР Союзы Оборона Халык Комиссары Урынбасары Советлар Союзы Маршалы иптәш ЖУКОВКА
Оборона Халык Комиссары урынбасары Кызыл Армиянең Баш Политик Идарәсе начальнигы генерал-лейтенант иптәш ЩЕРБАКОВКА
СССР Оборона Халык Комиссариатының Үзәк Месткомы председателе иптәш БАХАРЕВАГА

Оборона Наркоматы Үзәк идарәләренең Кызыл Армия өчен кораллар төзүгә 3.080.000 сум акча һәм 4.155.000 сумлык дәүләт заемнары облигацияләре җыйган работникларына минем сугышчан сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Ленинград фронты). «Безнең совет Ватаны өчен» дигән фотоплакат. ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

29 нчы ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

29 нчы январьга каршы төндә Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Төньяк Кавказ, Воронеж, Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Дон фронты гаскәрләре дошманның таркатылган группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Немецлар берәм-берәм һәм группалап коралларын ташлыйлар һәм пленга биреләләр. Н-че часть 240 кешене плен алды. Гвардия подразделениеләре дошманның күп кенә ныгытмаларын кулга төшерделәр һәм 190 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар. Трофейлар саны өзлексез артып тора.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм күп кенә участокларда дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Н-че часть сугышчылары дошман пехотасының контратакасын кире кайтарып, немецларның ныгытылган позицияләрен алдылар. 6 пулемет, 4 миномет, бер сугыш припаслары складь һәм бер радиостанция кулга төшерелде.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Н-че часть халык яшәп торган бер пунктны алды һәм ике рота дошман пехотасын юк итте. Икенче бер участокта безнең сугышчылар немецларның бер зур отрядын тар-мар иттеләр. Бер танк, 2 орудие, 13 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, сугышларның ике көне эчендә халык яшәп торган 33 пунктны азат итте һәм 20 километр алга китте. 300 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды, күп трофейлар кулга төшерелде. Безнең танкистлар һәм гвардиячe кавалеристлар, дошманның чолганып алынган группировкасыннан 3.000 ләп гитлерчыны кырдылар. 6.000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары, шул исәптән 3 генерал плен алынды.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че укчы часть подразделениеләре урам сугышларында 200 дән артык гитлерчыны кырдылар. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта безнең хәрәкәттәге группаларыбыз дошман тылына үтеп чыктылар һәм немецларның зур автоколоннасының чигенү юлын кистеләр. Дошманның автоколоннасын юк итү буенча сугышлар бара. Н-че частьның разведка отряды төнлә белән немецлар кулындагы, халык яшәп торган бер пунктка бәреп керде һәм аз гына сугышканнан соң бу пунктны алды. 3 танк, 12 автомашина, танкка каршы ата торган 4 орудие, бер сугыш припаслары складь һәм бер кием складь кулга төшерелде.

* * *

Литва ССР ның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның халык яшәп торган бер пункттагы гарнизонына һөҗүм иткән. Совет патриотлары полиция участогын туздырганнар һәм немецларның 3 складын яндырганнар. Икенче бер отрядның бер группа партизаннары дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Бер паровоз, сугыш техникасы төялгән платформалар һәм солдатлар утырган берничә вагон юк ителгән.

* * *

Немецларның моторлаштырылган 25 нче дивизиясе составындагы 35 нче полкның 9 нчы ротасыннан плен алынган обер-ефрейтор Юлиус Ванечек болай диде: «Унеча—Брянск юлында соңгы вакытларда бик күп поезд һәлакәтләре булды. Мин декабрь аенда партизаннарның шул районда гаскәрләр төяп бара торган 15 поездны юлдан чыгарганлыкларын беләм» Немецларның 293 нче пехота дивизиясенең 511 нче полкының 5 нче ротасыннан плен алынган ефрейтор Курт Магдебург болай диде: «Госпитальләрдән кайтучы солдатлар тимер юлларда бик күп диверсияләр һәм һәлакәтләр булуын сөйлиләр. Партизаннар эшелоннарга төнлә генә түгел, хәтта көндез дә аталар. Немец солдатларының рус партизаннарыннан куркуларын яшереп торырга урын юк».

„СОВЕТ УКРАИНАСЫ“ ИСЕМЛЕ ТАНКЛАР КОЛОННАСЫ

Н-че завод эшчеләре ватан сугышы фронтларыннан килгән шатлыклы хәбәрләрне производствода яңа күтәренкелек белән каршы алалар. Кызыл Армиянең җиңүле һөҗүме хезмәт фронты сугышчыларын тирән рухландыра, дошманны тармар итүне барлык көчләр белән тизләтергә чакыра.

Танклар колонналары, самолетлар эскадрильяләре төзүгә средство туплау буенча башланып киткән патриотик хәрәкәт безнең заводта да киң колач алды.

— Фронтка хезмәтебез һәм акчабыз белән ярдәм итик,—диделәр заводның эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре.

Начальнигы орденлы иптәш Регулянт булган цех коллективының инициативасы буенча заводта «Совет Украинасы» исемле танклар колоннасы төзелешенә средство туплау башланды. Бу цехның эшчеләре 15.000 сум акча җыйдылар. Мастерлардан Монета һәм Баев иптәшләр 250 шәр сум, стахановчы Петащук 200 сум керттеләр.

Украин кызы Валя Черткова митингта болай диде:

— Мин Украина җире өчен немец калбахәтләрдән тизрәк үч алу теләге белән яшим. «Совет Украинасы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 100 сум саклык акчамны бирәм.

Өлкән мастер Бондаренко танклар колоннасы төзелешенә 3.000 сум кертте.

— Мин Украина халкының улы. Туган илемне немец оккупантларыннан азат итү өчен барысын да эшләргә әзер торам,— диде ул.

Цех начальнигы иптәш Хмельницкий 1.000 сум кертте. Инженер-техник работниклар танклар төзелешенә 20.000 сум керттеләр. Гуревич, Байбеков, Яблонский һәм башкалар 5 әр йөз сум бирделәр. Завод буенча 250.000 сум акча җыелды. Средство туплау дәвам итә.

М. ШВАРЦЕР.

Агитаторлар эштә үрнәк күрсәтәләр

Безнең Актаныш районында 210 комсомолец агитатор булып эшли. Алар колхозчыларга ватан сугышы чорында алда торган бурычларны ныклап аңлаталар, аларны героик Кызыл Армиябезгә булышлык итүгә туплыйлар.

Агитаторлар үзләре һәрбер эштә үрнәк күрсәтәләр. Мәсәлән, Кәзкәй авылы комсомол оешмасын (секретаре иптәш Тимершина) алыйк. Бу оешмада агитация-масса эшләре ватан сугышы таләпләренә җавап бирерлек итеп оештырылган. Һәрбер комсомолец үзенең ялкынлы сүзе һәм практик эше белән колхоз производствосында яңа уңышлар өчен көрәшә. Бу колхоз районда иң алдынгылардан санала. Биредә, 1942 нче елда игеннәрне урып-җыю, дәүләткә ашлык тапшыру һәм башка хуҗалык эшләре уңышлы үтәлде. Хәзер язгы чәчүгә әзерлек эшләре тәгалләнү алдында тора.

Монда «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә средство туплау зур активлык белән үтте. Бу эштә дә комсомолецлар үрнәк күрсәттеләр. Агитатор иптәш Рәшитова сугышчан машиналар төзү өчен 5.000 сум акча, батыр сугышчыларга бүләк итеп 6 пот ашлык һәм бер сарык бирде. Комсомол оешмасы секретаре иптәш Тимершина 5.000 сум акча, 9 пот ашлык тапшырды. Алардан үрнәк алып оешмада учетта торучы 12 комсомолецның барысы да бу эштә актив катнаштылар. Алар, танклар колоннасы төзү фондына 29.200 сум средство җыеп тапшырдылар.

Комсомолец агитаторлардан үрнәк алып, бу патриотик хәрәкәттә барлык колхозчылар активлык күрсәттеләр. Берничә көн эчендә генә дә 102.000 сум акча, 600 пот ашлык һәм байтак кына сарык тапшырдылар.

Бу эшне оештыруда барлык комсомолецлар белән берлектә, колхоз председателе, агитатор иптәш Галиев аеруча активлык күрсәтте. Ул үзе Кызыл Армия фондына 25 пот ашлык, сугышчан машиналар төзү фондына 8.500 сум акча кертте.

Комсомолецлар, алдынгы агитаторлар буларак, үзләренең большевистик сүзләрен колхоз производствосында актив эшләре белән бәйлиләр. Комсомолецлардан Билалов, Хафизова һәм башкалар колхозның иң алдынгылары булып торалар. Агитатор иптәш Сәетова үзенең бригадасын 1943 нче елның язгы чәчүенә тулысы белән әзерләде инде.

Яңа Богады авыл комсомол оешмасында да агитация-масса эшләре киң җәелдерелгән. Бу колхозда барлык политик һәм хуҗалык эшләр алдынгылар рәтендә үтәлә. Танклар колоннасы төзүгә 160.000 сум акча һәм күп кенә ашлык җыеп тапшырылды.

«Ирек» колхозындагы һәм Тәләкәй авылындагы агитколлективлар да үзләренең эшләрен уңышлы башкаралар.

Ләкин шуны әйтергә кирәк. Безнең районда әле алдынгы агитколлективларның һәм агитаторларның уңышлы тәҗрибәләрен уртаклашу эше киң җәелдерелмәгән. Моны иң кыска вакыт эчендә оештырырга кирәк.

З. ЗАКИРОВА.

КҮРГӘЗМӘ АГИТАЦИЯНЕҢ КӨЧЕ

Партбюро секретаре иптәш Дубинин булган цехта күргәзмә агитациянең уңышлы яңа формасын кулланa башладылар. Анда аерым кешеләргә мөрәҗәгать иткән сүзләр белән кечкенә генә күләмдә плакатлар элеп куела. Бу форма үзенең хәрәкәтчәнлеген һәм нәтиҗәлелеген күрсәтте.

Комсомолец иптәш Безруков эшләгән урынга шундый плакат эленгән:

«Иптәш Безруков!

Син партизанка Таняны хәтерлисеңме? Комсомолецлар аның өчен дошманнан үч алырга ант иткәннәр иде. Без планнарыбызны арттырып үтәвебез белән немецлардан үч алабыз.

Ә син, иптәш Безруков, планыңны үтәмисең».

Турыдан-туры әйтелгән бу сүзләр иптәш Безруковка бик нык тәэсир иттеләр. Ул үз эшенә бик нык әһәмият бирә башлады. Нәтиҗәдә, декабрь ае планын 116 процент итеп үтәде.

Икенче плакат мастер иптәш Журавлев җитәкчелек иткән группаның эш урынына эленде. Анда:

«Иптәш Журавлев!

Нормаларны үтәү ул, фронтка сугышчан продукция бирү дигән сүз. Ә сезнең группада 7 кеше нормасын үтәми. Шуның нәтиҗәсендә фронтка җибәрелергә тиеш булган 8 изделье эшләнми кала.

Группадагы бу җитешсезлекне төзәтергә әле соң түгел. Иптәш Журавлев, сез группа җитәкчесе буларак, эш нормаларын үтәү һәм арттырып үтәүдә барлык эшчеләргә булышыгыз».

Бу плакатны укыганнан соң, иптәш Журавлев һәрбер эшчегә нормасын үтәүдә практик булышлык күрсәтте. Хәзер группада планнарын үтәмәүчеләр бөтенләй юк дип әйтерлек.

Күргәзмә агитациянең бу формасының көче, аның конкрет булуында. Чөнки анда теге яки бу җитешсезлек күрсәтеп кенә калынмый, анда кем гаепле икәнлеге һәм у. җитешсезлекнең нәрсәгә алып барганлыгы күрсәтелә. Тагын бу плакатның әһәмияте шунда, ул коллективны, аның аерым членнарын политик әһәмияткә ия булган конкрет бурычларны үтәүгә, фронтка ярдәм итүгә туплый.

А. КУЗНЕЦОВ.

ЭШЛЕКСЕЗ СЕКРЕТАРЬ

Норлат районының Киров исемендәге колхозның комсомол оешмасы секретаре иптәш Сабитова эшлексезлек күрсәтә. Комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында политик-тәрбия эшләрен оештырмый. Комсомол җыелышлары очраклы рәвештә генә үткәрелә.

Союздан тыш яшьләр арасында политик-тәрбия эшләренең тиешле югарылыкта булмавы нәтиҗәсендә, 1942 нче елда, бу оешмада комсомол сафларына бер генә кеше дә кабул ителмәгән.

ВЛКСМ ның район комитеты бу оешмага карата конкрет булышлыкны көчәйтергә һәм аның эшлексез секретарена карата чара күрергә тиеш.

Р. ХӘСӘНОВА.



Вахитов исемендәге жиркомбинатның ярдәмче хуҗалыгы работниклары язгы чәчүгә әзерләнәләр. Аларга комбинатның эшчеләре актив рәвештә булышалар. Механика мастерское стахановчылары Ш. Д. Гатауллин һәм П. К. Любцов иптәшләр эштән буш вакытларында ярдәмче хуҗалыкның инвентаре а ремонт ясарга йөкләмә алдылар. Рәсемдә: Гатауллин (уңда) һәм Любцов иптәшләр сабанны җыялар.

Б. Невзоров фотосы.

Нөркәй МТС ы тракторларга ремонт ясауны тәгәлләде

Нөркәй МТС ы коллективы, патриотик күтәренкелек һәм иптәш Сталинның приказы белән рухланып, 28 нче январьда тракторларга ремонт ясауны тәмамлады. Ремонтның сыйфаты яхшы. Хәзер МТС коллективы Теләнче Тамак МТС ына тракторлар ремонтлауда ярдәм итә.

ВКП(б) ның Ворошилов райкомы секретаре ГӘРӘЕВ.

МТС директоры БУЛАТОВ.

Политбүлек начальнигы АБДУЛЛИН.

Авыл хуҗалыгы кадрлары әзерләүгә игътибарны тагын да көчәйтик!

КОЛХОЗЛАРГА АГРОТЕХНИКЛАР

Арча районының Төрнәле участогында, агротехниклар әзерләү буенча 10 көнлек курслар үткәрелде. Курслар эше белән район җир бүлеге агрономы иптәш Ибәтуллин җитәкчелек итте. Бу участокка кергән колхозлардан курста 19 кеше катнашты. (Шулардан 12 се хатын-кызлар).

Шушы көннәрдә курс үзенең эшен тәмамлады. Укучыларның 10 сы 76 сәгатьлек программа материалын отличного һәм калганнары яхшы билгеләренә үзләштерделәр.

Менә иптәш Әскәров, ул, «3 нче интернационал» колхозында 8 ел агротехник булып эшләгән.

— Быелгы курс минем белемемне киңәйтте. Колхозчыларны югары, хәрби уңыш өчен көрәшкә туплау юлларын өйрәтте,—ди ул.

Шәфигулла бабай Насыйбуллинга 60 яшь инде. Ул 12 ел буенча Түбән Әзәк авылы колхозының яшелчәчелек бригадасы белән җитәкчелек итте. Бу чорда Шәфигулла бабай авыл хуҗалыгы үсемлекләрен үстерү, аларны тәрбияләү буенча күп кенә тәҗрибәләр һәм күнегүләр алды. Колхоз правлениесе быел аны агротехниклар әзерләү курсына җибәрде. Шәфигулла карт үзенең практик эшләрен теоретик белемнәр белән тагын да баетты. Ул курсны отлично билгесенә тәмамлады.

Курсны тәмамлаучылар барысы да үз колхозларына кайтып, практик эшкә керештеләр.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

ТРАКТОРНЫ ОТЛИЧНО ӨЙРӘНӘЛӘР

Машина-трактор станцияләренең колхозларга хезмәт күрсәтүләрен яхшырту өчен тракторлар һәм башка авыл хуҗалыгы инвентарьларының яхшы ремонтлануы белән бергә, аларны нык үзләштергән кадрлар да кирәк. МТС тагы кадрларның күп өлеше ватанны саклау өчен фронтка киттеләр. Алар урынына яшь кадрлар килделәр. Менә шуның өчен дә Кукмара МТС ы тракторларны отлично өйрәнгән кешеләр әзерләүгә нык әһәмият бирә.

Быел МТС 100 гә якын яңа, яшь тракторчылар әзерләргә тиеш. Хәзерге көндә 70 кеше тракторчылар әзерләү курсларында укыйлар. Бу иптәшләр тракторны һәм башка тагылма машиналарны практика һәм теория ягыннан яхшылап үзләштерү өчен бик нык тырышалар. Алар арасында Гарипова, Әхметшина, Галиева, Сафина, Гатин һәм Сөләйманов иптәшләр тракторларның төзелешен һәм хәрәкәт иттерү юлларын отлично үзләштерәләр. Алар, һичшиксез, алдагы көннәрдә дә илебезнең тырыш һәм оста тракторчылары булу өчен көрәшерләр.

ХАТЫН-КЫЗЛАР АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МАШИНАЛАРЫНДА

Норлат районының «Яңалиф» колхозында язгы чәчүгә әзерлек эшләре планлы рәвештә алып барыла. Колхоздагы 5 атлы чәчү машинасының 4 се ремонтланды инде. 24 сабанның 22 се ремонттан чыкты. Биредә авыл хуҗалыгы машиналарын өйрәнү буенча түгәрәк оештырылды. Бу түгәрәкнең эше белән агротехник Сираҗиев иптәш җитәкчелек итә. Хатын-кызлардан 15 кеше авыл хуҗалыгы машиналарының төзелешен зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Язгы чәчү вакытында алар шушы машиналарны хәрәкәткә китерәчәкләр.

А. ЗАРИПОВ, С. САДЫЙКОВ.

ЧЕРЧИЛЛЬ БЕЛӘН РУЗВЕЛЬТНЫҢ ТӨНЬЯК АФРИКАДА ОЧРАШУЫНА КАРАТА

ЛОНДОН, 27 январь. (ТАСС). Англия информация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, Черчилль Лондоннан 12 нче январьда кич белән киткән. Ул август аенда Каһирәгә һәм Москвага барган самолетта очкан. Касабланкада аны Англия һәм Америка офицерларының кечкенә бер группасы каршы алган. Бераз вакыттан соң самолетларга утырып, сөйләшүләрдә катнашучыларның Англия группасының башка членнары да килгән. Икенче көнне Касабланкага Вашингтоннан Америка Кушма Штатлары президенты Рузвельт очып килгән.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, штабларның членнары шәһәр якынындагы бер бинада очрашканнар һәм көндез дә, төнлә дә, бертуктаусыз, быелгы кампаниянең планнарын тикшергәннәр. Сөйләшүләр беткәннән соң матбугат конференциясе булган. Конференциядә Рузвельт, Черчилль, де Голль, Жиро һәм Америка һәм Англия хәбәрчеләреннән 60 кеше катнашкан.

Сөйләшүләр вакытында Рузвельт Марокко солтанын кабул иткән. Шулай ук ул Касабланкадан 70 миль ераклыктагы Лиоте портын караган. Анда Америка гаскәрләре берләшмәләренә инспекторлык иткән. Рузвельтның Америка гаскәрләре янына килеп чыгуы алар өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булган.

Рузвельтның һәм Черчилльнең матбугат вәкилләренә белдерүләре

НЬЮ-ЙОРК, 27 январь. (ТАСС). Америка матбугаты 24 нче январьда Касабланкада булган матбугат конференциясе турындагы хәбәрләрне игълан итә. Бу конференциядә Рузвельт һәм Черчилль үзләренең очрашулары турында белдерүләр белән чыкканнар.

Рузвельт үзенең чыгышында, бөтен дөньяда тынычлыкны бары тик Германиянең һәм Япониянең куәтен юк итү юлы белән генә яулап алырга мөмкин дигән мәсьәлә буенча тулы килешүгә ирешелгәнлекне белдергән. Рузвельт, бу очрашуны Германиянең, Италиянең һәм Япониянең «һичбер сүзсез капитуляциясе турындагы мәсьәлә буенча конференция» дип атарга тәкъдим иткән.

Рузвельт, үзенең Черчилль белән очрашуын беренче тапкыр но[...] нда [...] Төньяк Африкага Англия-Америка гаскәрләре төшерелгән [...] гәнлекне, ә соңыннан очрашу турындагы практик тәкъдимнең 1 нче декабрьда тикшерелгәнлеген әйткән.

Рузвельт Сталинның сөйләшүләрдә катнаша алмавына тәэссеф белдергән. Рузвельт, Верховный Баш Командующий Сталинның Кызыл Армия тарафыннан тормышка ашырыла торган бик яхшы һөҗүм планының авторы икәнлеген күрсәтеп үткән. Рузвельт, хәзерге сөйләшүләрнең тарихта әле тиңдәше булмаганлыкны белдергән. Аннан соң ул үзенең Черчилль белән якыннан дус икәнлеген аерым күрсәтеп үткән. Рузвельт, сүзендә дәвам итеп, Черчилль белән сөйләшүләр вакытында Англия һәм Америка берләшкән штаблары җитәкчеләренең, сугыш хәрәкәтләрен алып бару буенча үзәкләштерелгән бер дәм планга туры китереп, союздаш илләрнең ресурсларын берләштерү принципларын һәм методларын тикшергәнлекләрен әйткән.

Рузвельт, бөтен дөнья күләмендә көчле һөҗүм үткәреләчәген һәм көрәшне бик яхшы алып баручы Россиягә мөмкин булган бөтен материаль ярдәм күрсәтеләчәкне белдергән. Аннары Рузвельт болай дигән:

— Русларның һөҗүме киләчәктә дә Германиянең кешеләр ресурсларының кимүенә һәм Германиянең сугыш припаслары һәм материаллар запасларының тагын да азаюына китерәчәк дип исәп тотарга мөмкин. Шулай ук берләшкән илләр Кытайга да мөмкин булган бөтен ярдәмне күрсәтәчәкләр һәм шулай итеп Япониянең Ерак Көнчыгышта естен булырга маташуларын тәмам юк итәргә булышлык итәчәкләр. Берләшкән илләр күчәр илләрендәге халыкларга яки күчәр дәүләтләре контролендәге илләрнең халыкларына зыян китерергә уйламыйлар. Ләкин берләшкән илләр башка халыкларны дошман күрү, куркыту һәм кол итү идеологиясен юк итәчәкләр.

Рузвельт бу фикергә барлык берләшкән илләрнең кушылуларына ышануын белдергән. Аннары Рузвельт, Америка һәм Англия генеральный штаблары җитәкчеләренең, сугыш операцияләренең барлык мәсьәләләре буенча килешүгә ирешеп, сөйләшүләрне тәмам иткәнлекләрен әйткән. Рузвельт быелгы елның 1942 нче елга караганда уңышлырак булачагына ышануын белдергән.

Рузвельтның әйтүенчә, ул һәм Черчилль үзләренең Касабланкада булган сөйләшүләре де Голльның Жиро белән очрашуы өчен бик уңайлы мөмкинлек тудыра дип санаганнар. Аннан соң Рузвельт де Голльның һәм Жироның берничә көн киңәшмә алып барганлыкларын, аларның икесенең дә Францияне азат итәргә чын күңелдән тырышуларын һәм шуңа омтылуларын белдергән һәм, Франция армияләре, хәрби флоты һәм һава көчләре Францияне азат итүдә катнашачаклар, дигән. Чыгышының ахырында Рузвельт Американың кайбер гаскәрләренә инспекторлык иткәнлеген һәм алар яхшы коралланганнар, сугышырга теләп торалар дип тапканлыгын белдергән.

Рузвельттан соң матбугат вәкилләре алдында Черчилль белдерү белән чыккан. Ул, үзенең практикасында бу сөйләшүләрнең иң уңышлы сөйләшүләр булганлыгын белдергән. Черчилль болай дигән:

— Моннан элек әле мин беркайчан да шушындый дусларча үткән конференциядә катнашканым юк иде. Бу сөйләшүләрнең нәтиҗәләре союзникларның гаскәрләре җиңү өчен иң яхшы нигез бирәчәкләр.

Черчилль үзенең Сталинга соклачуын белдереп, Сталинның шулай ук Чан Кайшиның бу конференциядә катнаша алмауларына тәэссеф белдергән. Ләкин, аның әйтүенчә, аларның икесенә дә сөйләшүләрнең барышы турында тулы информация бирелгән.

Соңыннан Черчилль үзенең һәм Рузвельтның, бөтен дөньяга кайгы-хәсрәт һәм җимерeклек китергән җинаятьче көчләрнең һичбер сүзсез капитуляция ясауларына ирешергә кайчан гына булганга караганда да ныграк карар биргәнлекләрен әйткән.

ТӨНЬЯК АФРИКАДАГЫ СӨЙЛӘШҮЛӘР ТУРЫНДА ЖИРО ШТАБЫНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 28 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, генерал Жиро штабы түбәндәге белдерүне игълан иткән: «Әле яңа гына Төньяк Африкада союзникларның әһәмиятле конференциясе булып үтте. Шул уңай белән генерал Жиро Рузвельт һәм Черчилль белән, шулай ук союзниклар армияләренең җитәкчеләре белән очрашты. Франция өчен иң әһәмиятле булган нәтиҗәләргә ирешелде. Берләшкән милләтләр Францияне көрәшне беркайчан да туктатмаган, аны үз иленнән читтә дәвам иттерүче һәм яңадан үз территориясендә көрәшергә әзерләнүче союзник дип таптылар. Франциянең Тунистагы хәрәкәтләре аның үз территориясен азат итәргә карар биргәнлеген раслыйлар. Хәрби өлкәдә барлык мәсьәләләр буенча, шул исәптән Африкадагы Франция гаскәрләрен аларга кирәк булган иң яхшы кораллар белән беренче чиратта тәэмин итү турындагы мәсьәлә буенча да килешүгә ирешелде. Экономика һәм финанс өлкәсендә илдә һәм аннан читтә Франция интересларын саклау турында килешү ясалды.

Шуның естенә, шушы конференция уңае белән, генерал Жиро генерал де Голль белән очрашты. Аларның бу каракаршы очрашулары азатлык сугышында Франциянең тырышлыгын сештырырлык шартларны карый башларга мөмкинлек бирде.

Бу мәсьәлә буенча фикерләр алмашу дәвам итәчәк. Моннан соң һәрвакыт элемтәдә булырга карар бирелде.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Төньяк Кавказ). Төньяк Осетия территориясенә килеп кергән немец оккупантларны тар-мар итүдә фронтның бу участогында хәрәкәт итүче партизаннар отряды зур роль уйнады. Рәсемдә: безнең сугышчылар партизаннар отряды командирының ярдәмчесе иптәш К. белән очрашалар.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

29 нчы ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Воронеждан көнбатыштарак урнашкан безнең гаскәрләр шушы көннәрдә немец-фашист гаскәрләренә каршы һөҗүмгә күчтеләр. Каты сугышларның 3 көне эчендә безнең гаскәрләр халык яши торган 200 дән артык пунктны, шул исәптән **Касторное** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын, район үзәкләреннән: **Воловоны, Голосновканы, Землянскины, Гремячьены, Хохолны**, район үзәкләре һәм тимер юл станцияләре **Латнаяны, Курбатовоны, Прокуровоны, Набережноены** алдылар.

29 нчы январьда **Воронеж** фронты гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, **Новый Оскол** шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен адылар.

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре каты сугышлардан соң **Кропоткин** шәһәрен һәм зур тимер юл узелын һәм район үзәге **Темиргоевскаяны** алдылар.

* * *

28 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 400 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 3 тимер юл составын җимерделәр һәм 3 батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Дон фронты гаскәрләре гитлерчыларның таркатылган группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Сталинградның үзәк өлешенә якынрак районда 300 немец солдаты һәм офицеры юк ителде. 400 гә якын дошман солдаты, күп офицерлар һәм бер генерал плен алынды. Сталинградтан төньяктарак безнең частьлар чолганыш боҗрасын тагын да ныграк кыстылар һәм күп гитлерчыларны кырдылар. 25 орудие, 56 пулемет, бер бронемашина, 7 вездеход, 91 автомашина һәм 4 сугыш припаслары склады кулга төшерелде.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм көчләрнең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Немецлар, бик күп танклар һәм мотопехота китереп, каты каршылык күрсәтәләр. Совет частьлары дошманның контратакаларын кире кайтардылар һәм акрынлап алга бардылар. Безнең гаскәрләрнең сугышчан сафларын бомбага тотарга маташкан 14 немец самолетына каршы капитан Кузьмин җитәкчелегендәге совет очучыларыннан 5 истребитель атака ясады. Бик каты һава сугышында совет очучылары дошманның 6 самолетын бәреп төшерделәр. Безнең истребительләр үз аэродромнарына югалтусыз кайттылар.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары халык яши торган 6 пунктны алдылар һәм немецларның 500 кешедән торган штрум батальонын бөтенләй юк иттеләр. 18 орудие, 14 пулемет, 6 миномет, 60 автомашина һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. Н-че частьның истребительләре группасы дошман урнашкан урынга барып чыгып, бер ротага якын немец пехотасын юк итте

* * *

Воронеждан көнбатыштарак урнашкан безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Сугышларның 3 көне эчендә бу участокта 14.000 нән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды. Безнең частьлар бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

Касторное шәһәрендә тимер юл станциясендә дошманның 2.000 ләп солдат һәм офицерлар утырган 2 эшелоны кулга төшерелде. Шунда ук немецларның бер дивизиясенең штабы плен алынды.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть берләшмәләре берничә урында Кубань аркылы кичтеләр һәм каты сугышлар нәтиҗәсендә Кропоткин шәһәрен алдылар. Урам сугышларында совет сугышчылары меңнән артык гитлерчыны юк иттеләр, немецларның 5 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар. Пленныйлар алынды һәм күп трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танк һәм мотопехота подразделениеләре халык яши торган бер пункттагы немецлар гарнизонын тар-мар иттеләр. 150 немец солдаты һәм офицеры пленга бирелде. 2 сугыш припаслары склады һәм бер азык склады кулга төшерелде.

* * *

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды берничә көн буена немецларның җәза экспедициясенә каршы сугыш алып барган. Партизаннар 200 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк иткәннәр һәм гитлерчыларны чигенергә мәҗбүр иткәннәр. Витебск партизаннарының икенче бер отряды ике атна эчендә немецларның 7 эшелонын юлдан чыгарган. 6 паровоз һәм 137 вагон җимертелгән. Шул ук вакыт эчендә совет патриотлары 10 күперне шартлатканнар, 5 километр озынлыкта тимер юлны җимергәннәр һәм дошманның 15 йөк авомашинасын юк иткәннәр.

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Захаро-Обливский хуторында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «27 нче декабрьда немецлар Захаро-Обливский хуторына бәреп керделәр, барлык ирләрне, ничә яшьтә булуларына карамастан, йортлардан һәм яшеренгән урыннардан куып чыгардылар һәм атып үтерделәр. Гитлерчы палачлар 78 яшьлек Кондрат Осадченкоэны, 74 яшьлек Константин Забродинны, 55 яшьлек Иван Семиявченконы, 19 яшьлек Иван Жуковны, 19 яшьлек Иван Проновны, 18 яшьлек Николай Гладченконы, 16 яшьлек Федор Пономаревны, 32 яшьлек Игнат Вчерашневны, 28 яшьлек Виктор Поповны, 30 яшьлек Михаил Поповны, 37 яшьлек Сергей Косенконы һәм башка колхозчыларны үтерделәр. Шуның өстенә фашист ерткычлар 6 пленный совет сугышчысын аттылар. Немецлар барлыгы 40 кешене атып һәм ерткыч төстә газаплап үтерделәр. Гражданнар халкын кан түгеп җәзалаганнан соң гитлерчылар бөтен җирдә талау башладылар. Хутордан чигенгән чакта немецлар 13 йортка, колхозның 4 амбарына һәм дуңгыз абзарына бензин сибеп ут төрттеләр». Актка өлкән лейтенант Т. Рогов, кызылармеец Т. Козлов, Захаро-Обливский хуторы кешеләреннән М. Школенко, Я. Яровенко, К. Осадченко һәм башкалар кул куйды.

СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ХӘРБИ УҢЫШЛАРЫ ТУРЫНДА ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

ИРАН

„Ленинград блокадасын өзү—Совет стратегиясенең гаять зур уңышы“

ТАҺРАН, 28 январь. (ТАСС). Таһранда чыга торган барлык газеталар Кызыл Армиянең һөҗүменә зур игътибар бирәләр. Совет гаскәрләренең уңышлы операцияләре турындагы хәбәрләр күренерлек урыннарга урнаштырыла. Газеталар һөҗүм бара торган районнарның карталарын урнаштыралар.

«Этталәгать» газетасы болай дип яза: «Кызыл Армия, быел җәй көне немецларның басымына каршы ныклы оборона оештырып, хәзерге кышкы контрудар өчен беренче шартларны әзерләде. Быел совет гаскәрләре һөҗүмгә үткән елга караганда иртәрәк күчтеләр һәм киң фронтта дошманны көнбатышка алып ташлыйлар. Бөтен дөньяның игътибары Советлар Союзындагы киң сугыш кырларына, Кызыл Армия тарафыннан дошманга җимергеч ударлар ясала торган мәйданнарга юнәлдерелгән».

«Кәйхан» газетасының фикеренчә, совет гаскәрләренең җиңүләре Совет—Германия сугышында яңа чор дигән сүз. Газета совет гаскәрләре һөҗүменең кызу темплар белән баруын һәм шуның нәтиҗәсендә немец гаскәрләренең паникага бирелеп үзләренең барлык коралларын ташлауларын әйтеп үтә.

Шул ук газета Ленинград блокадасын өзүнең әһәмиятенә махсус мәкалә багышлаган. Газета болай дип яза: «Ленинград немецлар һөҗүменең беренче зур объектларыннан берсе иде. Ленинградлыларның үз шәһәрләрен геройларча саклаулары агрессор гаскәрләрен Ленинград капкасы янында озак вакыт тотып торды. Сугыш беткәннән соң галимнәр анык тарихын язган чакта бу тарихның иң гүзәл сәхифәләреннән берсе ленинградлыларның батырлыгы турында булачак. Ленинград блокадасын өзү — совет стратегиясенең гаять зур уңышы. Ул сугышның барышына зур йогынты ясар. Шулай ук Кызыл Армиянең бу җиңүенең мораль яктан да гаять зур әһәмияте бар. Ул немецлар тарафыннан кол ителгән халыкларны үзләренең азатлыклары өчен көрәшне көчәйтүгә рухландырыр».

ТӨРКИЯ

„КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ТОРГАН САЕН СОКЛАНУ ТУДЫРАЛАР“

ИСТАМБУЛ, 28 январь. (ТАСС). Төркия матбугаты Кызыл Армиянең уңышлары турындагы хәбәрләргә киң аңлатмалар бирүен дәвам иттерә. «Яңы Сабах» газетасы, Совет—Германия фронтындагы сугышларның барышы Кызыл Армиянең һөҗүм операцияләренең алдан ук бик җентекләп хәзерләнгәнлеген күрсәтә, ди. Газета болай дип яза: «Совет гаскәрләре инде зур җиңүләргә ирештеләр. Сталинград районында тимер боҗра белән кысып алынган Германия гаскәрләре бөтенләй диярлек юк ителделәр. Немецлар үткән елны ук инде Ленинградны тиздән алачакларын хәбәр иткәннәр иде. Быел Ленинград блокадасы өзелде. Кызыл Армия гаять әһәмиятле стратегия үзәкләренә таба алга бара. Кавказда Германия гаскәрләре удар астында торалар». Газета, немецлар үзләренә гаять зур корбаннарга төшкән җәйге һөҗүмнәренең барлык нәтиҗәләрен югалталар, ди.

«Истикълал» газетасы Шәүкәт Билгинның мәкаләсен басып чыгарды. Ул болай дип яза: «Хәзерге сугышта иң һәйбәт һәм әһәмияте ягыннан иң зур вакыйгаларның берсе—Сталинград янында немец гаскәрләре дучар булган фаҗигале язмыштан гыйбарәт. Әле күптән түгел генә Сталинградка таба омтылган немецлар, русларның бу каршылык күрсәтүе үзәге инде «юк ителде» дип һәм күчәр гаскәрләре «Волганың бу ачкычын үз кулларына алдылар» дип мактанганнар иде. Бераз гына вакыт үткәч, немецлар армиясе Сталинградка килү юлларында тулы һәлакәткә очрады». Аннары автор, Ленинград блокадасының да өзелгәнлеген искә алып, шулай итеп ике әһәмиятле пунктта немецларның позицияләре юк ителгәнлекне әйтә. «Таң» газетасы редакторы Сертель, Совет—Германия фронтында үткән кышта булган хәлне быелгы кышта булган хәл белән чагыштырып, хәзер Кызыл Армиянең тагын да көчлерәк һәм уңышлырак һөҗүм алып баруын һәм немецларга тагын да зуррак ударлар ясавын әйтеп үтә.

«Соң телеграф» газетасы күзәтчесе, Совет—Германия фронтындагы хәлгә тулы анализ ясап, «тарихта әле ялгыш башланган сугышларда отып чыгу шикелле хәл беркайчан да булганы юк иде» дип немецларның исләренә төшереп үтә. Автор бу сугышта Германиянең, әлбәттә, җиңеләчәген күрсәтә.

РИМНЫ БОМБАГА ТОТУ МӨМКИНЛЕГЕ ТУРЫНДА ИДЕННЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 28 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Римны бомбага тотарга мөмкинме икәнлеге турында Иденга түбәнге палатада сорау бирелгән. Моңа җавап итеп Иден үзенең үткән атнада палатада белдерү ясаганлыгын әйткән. Бу белдерүдә итальяннарның Лондонны бомбага тотарга ни дәрәҗәдә хаклары булган булса, шул ук дәрәҗәдә англичаннарның да Римны бомбага тотарга хаклары барлыгы һәм әгәр дә сугышның барышы мондый хәрәкәтләрне кирәкле һәм муафыйк дип тапса, хөкүмәтнең һичбер икеләнмичә бу эшкә барачагы әйтелгән иде.

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 28 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәргә караганда, союзниклар гаскәрләре Уссельтиа үзәнендә һәм аннан көнчыгыштарак булган таулы районнарда үзләренең күптән түгел югалткан берничә позицияләрен яңадан кайтарып алганнар.

Авиация күчәр державалары кулында калган аэродромнарны бик нык бомбага тота.

ЛОНДОН, 28 январь. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә Англия патрульләре Триполидан 70 километр көнбатыштарак Сабарата районында дошман белән бәрелештә булганнар. 27 нче январьга каршы төндә Англия авиациясе Көньяк Италиядәге тимер юл объектларын уңышлы рәвештә бомбага тоткан.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — „*Башмагым*“.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 31 нче январьда, көндезге 12 сәгатьтә — „*Таймасовлар*“, кич — *концерт-бал*. Бөтен җыелган акча оборона фондына биреләчәк.

Зур драма театры. Бүген—„*Минем улым*“, 31 нче январьда көндез һәм кич—„*Маскарад*“.

Дәүләт циркы. Бүген—*зур цирк тамашасы* һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татар дәүләт филармониясе. 1 нче февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Усман *Альмиев концерты*. Соңыннан танецлар. Концерт кич 8 сәгать 30 минутта башлана. Бөтен җыелган акча „Совет актеры“ исемле танклар колоннасы төзү фондына биреләчәк.

„Электро“ — „*Син сокландым*“.

„Унион“—„*Котовский*“.

„Пионер“ көндез—„*Ялгыз җилкән күренә*“, кич — „*Антон Иванович ачулана*“.

„Чаткы“—„*Алтын кул*“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 628 „КРАСНАЯ ТАТАРИЯ“ һәм „КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН“ нәшриятелствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 185